КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 2 май г.Казань № 659

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Мәгариф өлкәсендә грантлар турында» 2021 ел, 13 август, 708 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Мәгариф өлкәсендә грантлар турында» 2021 ел, 13 август, 708 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 15 ноябрь, 1078 нче; 2022 ел, 29 июнь, 613 нче; 2022 ел, 2 сентябрь, 956 нчы; 2023 ел, 3 февраль, 92 нче; 2023 ел, 24 апрель, 520 нче; 2023 ел, 28 август, 1033 нче; 2023 ел, 25 сентябрь, 1184 нче; 2024 ел, 2 декабрь, 1087 нче; 2025 ел, 26 март, 173 нче; 2025 ел, 29 сентябрь, 777 нче; 2025 ел, 4 декабрь, 1043 нче; 2025 ел, 16 декабрь, 1098 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбулада «шулай ук физик затларга – товарлар, эшләр, хезмәтләр җитештерүчеләргә» сүзләрен «физик затларга» сүзләренә алмаштырырга;

1 пунктның өченче – алтынчы абзацлары үз көчен югалткан дип танырга;

2 пунктның дүртенче – җиденче абзацлары үз көчен югалткан дип танырга;

әлеге карар белән расланган «Иң яхшы билингваль балалар бакчасы» гранты турындагы нигезләмәдә:

2 пунктның икенче абзацында татар текстында «мәгълүмат» сүзеннән соң «грант бирү өчен бюджет ассигнованиеләре Министрлыкка җиткерелгән көннән соң килә торган көннән алып 10 эш көне эчендә» сүзләрен өстәргә;

37 пунктта «шәхси счетларга» сүзләрен «счетларга» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган «Гомуми белем бирү оешмасында предметларны укытуны камилләштерү буенча «Безнең яңа укытучы» проектын гамәлгә ашыруга грант бирү турындагы нигезләмәдә:

1 пунктта татар текстында «Әлеге Нигезләмә» сүзләреннән соң «2025 елда үткәрелгән сайлап алу нәтиҗәләре буенча» сүзләрен өстәргә;

4 пунктта:

беренче абзацта «Ел саен» сүзләрен «2025 елда үткәрелгән сайлап алу нәтиҗәләре буенча» сүзләренә алмаштырырга;

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Грант 2025 елның 1 сентябреннән алып 2026 елның 31 маена кадәр тугыз ай эчендә ай саен грант бирү турындагы килешүдә (алга таба – Килешү) билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда 10,0 мең сум күләмендә бирелә.»;

6 пунктның сигезенче абзацы үз көчен югалткан дип танырга;

7 пунктта:

беренче абзацта «грант бирелгән елның 1 сентябреннән алып грант бирү елыннан соң килә торган елның 31 маена кадәр» сүзләрен «2025 елның 1 сентябреннән алып 2026 елның 31 маена кадәр» сүзләренә алмаштырырга;

икенче абзацта «грант бирү елыннан соң килә торган елның» сүзләрен «2026 елның» сүзләренә алмаштырырга;

21 пунктта «шәхси» сүзен төшереп калдырырга;

22 пунктның беренче абзацында «грант бирү елыннан соң килә торган елның» сүзләрен «2026 елның» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган «Безнең яңа профессионал» гранты турындагы нигезләмәдә:

1 пунктта татар текстында «Әлеге Нигезләмә» сүзләреннән соң «2025 елда үткәрелгән сайлап алу нәтиҗәләре буенча» сүзләрен өстәргә;

4 пунктта:

беренче абзацта «Ел саен» сүзләрен «2025 елда үткәрелгән сайлап алу нәтиҗәләре буенча» сүзләренә алмаштырырга;

өченче абзацта «грант бирү турында карар кабул ителгән елдан соң килә торган елның» сүзләрен «2026 елның» сүзләренә алмаштырырга;

6 пунктның бишенче – сигезенче абзацлары үз көчен югалткан дип танырга;

7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Грант бирү нәтиҗәсе – 2025 елның 1 сентябреннән 2026 елның 31 маена кадәр чорда грант алучы тарафыннан индивидуаль проект гамәлгә ашырылу. Грант бирү нәтиҗәсенә 2026 елның 10 июненнән дә соңга калмыйча ирешелергә тиеш.»;

22 пунктта «шәхси» сүзен төшереп калдырырга;

23 пунктның беренче абзацында «грант бирү елыннан соң килә торган елның» сүзләрен «2026 елның» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган «Безнең яңа тәрбияче» гранты турындагы нигезләмәдә:

1 пунктта татар текстында «Әлеге Нигезләмә» сүзләреннән соң «2025 елда үткәрелгән сайлап алу нәтиҗәләре буенча» сүзләрен өстәргә;

4 пунктта:

беренче абзацта «Ел саен» сүзләрен «2025 елда үткәрелгән сайлап алу нәтиҗәләре буенча» сүзләренә алмаштырырга;

өченче абзацның икенче җөмләсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Килешүдә билгеләнгән тәртип нигезендә һәм сроклар эчендә грантның 40 мең сум күләмендә беренче өлеше грант алучыга грант бирү турында килешү (алга таба – килешү) төзелгән көннән алып 10 эш көне эчендә күчерелә, грантның 40 мең сум

күләмендә икенче өлеше грант алучыга 2026 елның 30 апреленнән дә соңга калмыйча күчерелә, грантның 40 мең сум күләмендә өченче өлеше грант алучыга 2026 елның 31 августыннан да соңга калмыйча күчерелә.»;

6 пунктның бишенче – сигезенче абзацлары үз көчен югалткан дип танырга;

7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Грант бирү нәтиҗәсе – 2025 елның 1 сентябреннән 2026 елның 31 августына кадәр чорда индивидуаль проектны гамәлгә ашыру. Грант бирү нәтиҗәсенә 2026 елның 31 августыннан да соңга калмыйча ирешелергә тиеш.»;

22 пунктта «шәхси» сүзен төшереп калдырырга;

23 пунктның беренче абзацында «грант бирү елыннан соң килә торган елның» сүзләрен «2026 елның» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган «Безнең яңа өстәмә белем бирү педагогы» гранты турындагы нигезләмәдә:

1 пунктта татар текстында «Әлеге Нигезләмә» сүзләреннән соң «2025 елда үткәрелгән сайлап алу нәтиҗәләре буенча» сүзләрен өстәргә;

4 пунктта:

беренче абзацта «Ел саен» сүзләрен «2025 елда үткәрелгән сайлап алу нәтиҗәләре буенча» сүзләренә алмаштырырга;

өченче абзацта «грант бирү турында карар кабул ителгән елдан соң килә торган елның» сүзләрен «2026 елның» сүзләренә алмаштырырга;

6 пунктның бишенче – сигезенче абзацлары үз көчен югалткан дип танырга;

7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Грант бирү нәтиҗәсе – 2025 елның 1 сентябреннән 2026 елның 26 маена кадәр чорда индивидуаль проектны гамәлгә ашыру. Грант бирү нәтиҗәсенә 2026 елның 31 маеннан да соңга калмыйча ирешелергә тиеш.»;

22 пунктта «шәхси» сүзен төшереп калдырырга;

23 пунктның беренче абзацында «грант бирү елыннан соң килә торган елның» сүзләрен «2026 елның» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин